Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Чәчәкле авыл җирлегенең Йолдыз торак пунктында
2025 елда гражданнардан үзара салым кертү турында:

22.11.2024 № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Чәчәкле авыл җирлегендә Йолдыз торак пунктында гражданнар җыены
карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Чәчәкле авыл җирлеге территориясендә Йолдыз торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә

2. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрергә:

1) Йолдыз торак пунктында урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (энергияне саклаучы яктырткычларны һәм урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

2) Йолдыз торак пункты территориясен төзекләндерү (юлларны кардан чистарту, җәйге вакытта территорияне чаптыру, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

3) Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүп-чарларны бетерү (рөхсәтсез чүп-чарларны бетерү шартнамәсе буенча эшләр һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү, (каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү өчен контейнерлар сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) Йолдыз торак пунктында.».

3. Әлеге карарны Чәчәкле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерү, Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:/spasskiy.tatarstan.ru) бастырып чыгару, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгару.

Халык җыенында рәислек итүче,
Спас муниципаль районының
Чәчәкле авыл җирлеге башлыгы: Р.Р. Фәисханов